# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ЯҢА БҮЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«31» январь 2020 ел  Яңа Бүләк авылы  № 2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварендәге 8-ФЗ санлы Федераль закон, «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварендәге 61 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» ТР Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 февраленнән Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе  М.С.Сагетдинов

Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31.нче январе 2 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 2712,02 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 1989,67 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1423,17 |
| **Барлыгы:** | 6124,86 |

Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31.нче январе 2 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кафенгә төрү | 500 |
| 3. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 2212,02 |
| 4. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 1989,67 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1423,17 |
| **Барлыгы:** | 6124,86 |